РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» март 2025г. г. Альметьевск № 351

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2025 елның 6 мартындагы 02-01-24 номерлы протестын карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»2021 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 111 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 231 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 259 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 300 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

- «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау» 3 бүлегенең 3.4 пунктындагы икенче абзацында «контроль чаралар үткәрү турында» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясында күрсәтелгән чаралар күрә» сүзләрен өстәргә;

- «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау» 3.11 бүлегенең 3.11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Профилактик визит профилактик әңгәмә рәвешендә контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бара торган урынында яисә видео-конференция-элемтә яисә «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла;

- «Контроль чараларны һәм контроль гамәлләрне гамәлгә ашыру» 4 бүлегенең 4.21 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

- «Контроль чараларны һәм контроль гамәлләрне гамәлгә ашыру» 4 бүлегенең беренче абзацын һәм 4.23 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.23. Контроль чараны үткәргәндә контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә тикшереп торырга вәкаләтле вазыйфаи зат бурычлы:

1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң, контрольдә торучы затка, аларны бетерү срокларын, шулай ук федераль законда контроль рәвеше турында каралган башка чараларны күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирергә;»;

- «Судка кадәрге шикаять» 6 бүлегенең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1 Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдә торучы затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль (күзәтчелек) чаралар һәм мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү турында карарлар;

2) контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актлары, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр;

3) контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында контроль (күзәтчелек) органы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) ;

4) контроль объектларын хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертү турында карарлар;

5) контрольдә торучы затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турында карарлар;

6) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган профилактик һәм (яисә) контроль (күзәтчелек) чаралары йомгаклары буенча контрольдә торучы затларга яисә контроль объектларына карата контрольдә тотыла торган башка карарлар;

- «Судка кадәрге шикаять» 6 бүлегенең 6.9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»2020 елның 31 июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 4 өлешенең 1-3 пунктларында каралган нигезләр буенча шикаять бирелгән очракта, шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында контроль (күзәтчелек) чарасының яисә мәҗбүри профилактик визитның исәп номеры»;

- «Судка кадәрге шикаять» 6 бүлегенең 6.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) контроль төрләренең бердәм реестрында контроль объектының исәп номеры (контроль объектын хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертү турындагы карарга шикаять белдергәндә).»;

- «Судка кадәрге шикаять» 6 бүлегенең 6.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.15. Шикаять контроль орган җитәкчесе тарафыннан судка кадәр шикаять бирү системасында теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш. Контроль объектларын хәвеф-хәтәр категориясенә кертү турындагы карарга контрольдә торучы затның шикаяте биш эш көненнән дә артык булмаган вакытта карала.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар; икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы | Р.Е. Әфләтунова